КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 март г.Казань № 120

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 февраль, 151 нче карары белән расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2022 ел, 22 февраль, 151 нче карары белән (Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 02 август, 746 нчы, 2022 ел, 29 декабь, 1440 нче, 2023 ел, 4 февраль, 99 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктның уникенче абзацында «мөһере» сүзеннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә.

2. Бу карар (2024 елның 1 июненнән үз көченә керә торган 1 пунктның өченче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин